РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Клянчеевского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Клянчеево, 422836
тел./факс 8(84377)33-4-31
ОГРН 1061672017990
ИНН/КПП 1622004620/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Келәнче авылы, 422836
тел./факс 8(84377)33-4-31
ОГРН 1061672017990
ИНН/КПП 1622004620/162201001

# КАРАР

**24 сентябрь 2018 ел** **№ 10**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Кама Тамагы районы Келәнче авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы Келәнче авыл җирлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:
   “2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган, көндезге уку рәвеше буенча укучы студентлардан кала һәр кешедән 500 сум үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча билгеләнгән эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

   *** Җирлек территориясен яшелләндерү һәм төзекләндерү өчен:**
   *** Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
   *** Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү:**

***   Каты коммуналь  калдыкларны жыю һәм ташу  эшчәнлеген оештыру.**

“ӘЙЕ”                    “ЮК”

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35,

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур.,

шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе                                        Д.А.Кадыров.